# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2023 елның «25» сентябре № 124

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының аерым норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Өтәшкә авыл җирлеге Советының белешмәләрен һәм норматив-хокукый актларын актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Советы карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2015 елның 21 июлендәге 214 номерлы карары «2014 елның 04 ноябрендәге 167 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында»;

- 2016 елның 15 апрелендәге 36 номерлы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында».

2. «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында

белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 2 июнендәге 38 номерлы карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, һәм шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **А. А. Клопов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486